**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КОШКИ-НОВОТИМБАЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШКИ-НОВОТИМБАЕВО АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422383 с. Кошки-Новотимбаево, ул. Писателей, 16

422383 Кошки-Новотимбаево авылы, Язучылар урамы, 16

тел. (84373) 52-6-31, факс 52-6-31, e-mail: Kntm.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559501, ИНН/КПП 1638001582/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 .11. 2023** **№ 30-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль Законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге Советына таянып Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки –Новотимбаево авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының тәкъдим ителгән проектын (алга таба – Устав проекты) беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Устав проекты буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Кошки-Новотимбаево авылы, Язучылар урамы, 16 йорт; Тайба-Тауш авылы ,сенин урамы, 7 йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru.
7. Устав проекты буенча ачык тыңлауларны 2023 елның 22 декабренә 14:00 сәгатьтә кошка-Новотимбай авыл мәдәният йорты бинасында билгеләргә.
8. Комиссиягә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлаулар турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә Устав проектын тикшерү һәм килгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.
9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге башлыгы Н.П. Сапожниковка йөкләргә.

**Җитәкче** **Н.П. Сапожников**